РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ТОЙГИЛЬДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423974, РТ. Муслюмовский район, с.Тойгильдино, ул.Центральная д.4/2,
*Toy.Mus@tatar.ru* тел. (8-85556) 3-46-31
ИНН 1629003872, КПП 162901001, ОГРН 1061687001188, ОКАТО 92242875000.

**КАРАР № 9**

Тойгелде авылы 07.04.2021 ел

**«Тойгелде авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитетының 25 февраль 2017 ел, 4 нче номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитетының 25 февраль 2017 ел, 4 нче номерлы карары белән расланган « Тойгелде авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гарызнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында адрес буенча: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/toigildi.htm, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тойгелде авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе: Фәйзуллина Э.Н.